КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1262

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

I бүлекнең 3 пунктындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә мәшгуль хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация хезмәткәрләре, Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация хезмәткәрләре (алга таба – мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре) эш хакы (хезмәткәр хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:»;

II бүлекнең 1 пунктындагы таблицаның «кече тәрбияче» юлындагы 5 графада «10 020» саннарын төшереп калдырырга;

III бүлектә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гомуми белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләре өчен эш вакыты озынлыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогика эше сәгатьләре нормасы) эш вакытының кыскартылган озынлыгыннан чыгып атнага иң күбе 36 сәгать билгеләнә,

ул үз эченә укыту (уку) эшен, тәрбия, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи йөкләмәләрдә һәм эш вакыты режимында каралган башка педагогика эшләрен ала.»;

3.1 пунктчаның сигезенче абзацында «(рус булмаган)» сүзен төшереп калдырырга;

3.6 пунктчаның тугызынчы абзацында «15» саннарын «20» саннарына алмаштырырга;

V бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Язмача эшләр тикшерү (дәфтәрләр тикшерү) өчен түләү түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{nz}^{pt} = \left(\sum O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P\right) \times D_{pt},$$

монда:

$B_{nz}^{pt}$ – язмача эшләр тикшерү (дәфтәрләр тикшерү) өчен түләүләр күләме;

$O_b$ – гомуми белем бирү оешмасының педагогика хезмәткәренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$H_f$ – гомуми белем бирү оешмасында предмет буенча педагогика эшен алып баруның гамәлдәге сәгатьләре саны;

$Y_f$ – гомуми белем бирү оешмасында педагогика хезмәткәре күрсәтә торган хезмәтләрнең гамәлдәге саны;

$H_N$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән гомуми белем бирү оешмаларында педагогика хезмәткәрләренең эш хакын база ставкасы өчен сәгатьләр нормасы;

$Y_N$ – гомуми белем бирү оешмасында педагогика хезмәткәрләре күрсәтә торган хезмәтләрнең норматив саны;

P – китап чыгару продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, ләкин төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаска тиеш;

$D_{pt}$ – язма эшләрне тикшергән (дәфтәрләр тикшергән) өчен өстәмә түләү күләме, ул 1 нче таблицасында китерелгән.»;

VI бүлектә:

3 таблицаның 9 пунктындагы 3 графада «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфасы буенча» сүзләрен өстәргә;

4 пунктның унынчы абзацында «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе Мәгариф министры)» сүзләрен - «Россия Федерациясе Министра просвещения (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе Мәгариф министры)» сүзләренә, «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)» сүзләрен «Россия Федерациясе Министерства просвещения (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.8 пунктча өстәргә:

«5.8. Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында педагогика хезмәткәрләре һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{sr} = (O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P) \times D_{sr},$$

монда:

$B_{sr}$ – хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр;

$O_b$ – гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$H_f$ – гомуми белем бирү оешмасының педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$Y_f$ – мәгариф хезмәткәрләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең факттагы саны;

$H_N$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлеге тарафыннан билгеләнгән гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең хезмәт хакын база ставкасы өчен сәгатьләр нормасы;

$Y_N$ – гомуми белем бирү оешмасында педагогика хезмәткәрләре күрсәтә торган хезмәтләрнең норматив саны;

P – китап чыгару продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, ләкин төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаска тиеш;

$D_{sr}$ – хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр 28 процент күләмендә билгеләнә.»;

14 пунктта «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфасы буенча» сүзләрен өстәргә;

15 пунктта «белем бирү» сүзләрен «гомуми белем бирү» сүзләренә алмаштырырга;

15.2 пунктчада «белем бирү» сүзләрен «гомуми белем бирү» сүзләренә алмаштырырга;

15.11 пунктчада:

бишенче абзацка «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфасы буенча» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондының 16 проценты күләмендә кабул ителә (укытучылар һәм мөгаллимнәр вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш).»;

VII бүлектә:

3 пунктның беренче абзацында «структур бүлекчәләр җитәкчеләренә,» сүзләреннән соң «урта һәм әйдәүче буын һәм җитәкче составтагы мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган мәдәният хезмәткәрләренә, урта медицина һәм фармацевтика персоналының, табиблар һәм провизорларның һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган медицина хезмәткәрләренә» сүзләрен өстәргә;

15 таблицаның 9 пунктындагы 2 графада «интеллекты бозылган» сүзләрен «психик үсеше тоткарлануы белән, аутистик үсеше бозылулары белән, катлаулы дефектлар белән һәм акыл үсеше артта калган балалар» сүзләренә алмаштырырга;

VIII бүлекнең 16 таблицасына асъюлга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мәктәпара уку комбинатларында укучылар контингенты 0,5 коэффициенты белән исәпкә алына.»;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

«Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалары берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикаларының ведомство (тармак) бүләкләре, алар өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә»:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе просвещения министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)»;

түбәндәге эчтәлекле 1.8, 1.9 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.8. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләр тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре»; |

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.5 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.5. | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы» билгесе»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

III бүлектә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләре өчен эш вакыты (эш хакы ставкасы өчен педагогика эше сәгатьләре нормасы) мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләре өчен эш вакытының кыскартылган озынлыгыннан чыгып, атнасына 36 сәгатьтән артмаган күләмдә билгеләнә, ул укыту (уку) эшен, тәрбия эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи йөкләмәләрдә һәм эш вакыты режимында каралган башка педагогик эшне үз эченә ала.»;

3.2 пунктның тугызынчы абзацында «15» саннарын «20» саннарына алмаштырырга;

V бүлектә:

4 пунктның унынчы абзацында «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе Мәгариф министры)» сүзләрен - « Россия

Федерациясе просвещения министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының)» сүзләренә, «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының)» сүзләрен «Россия Федерациясе просвещения министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының)» сүзләренә алмаштырырга;

12.11 пунктның бишенче, җиденче абзацларына «һәм төп вазыйфасы (укытучылар һәм мөгаллим вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

13 пунктта «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфасы буенча» сүзләрен өстәргә;

VI бүлектә:

3 пунктның беренче абзацында «структур бүлекчәләр җитәкчеләренә,» сүзләреннән соң «урта медицина һәм фармацевтика персоналының, табиблар һәм провизорларның һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган медицина хезмәткәрләренә» сүзләрен өстәргә;

11 таблицаның 1 пунктындагы 2 графада «интеллекты бозылган» сүзләрен «психик үсеше тоткарлануы белән, аутистик үсеше бозылулары белән, катлаулы дефектлар белән һәм акыл үсеше артта калган балалар» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

«Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикаларының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе просвещения министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)»;

түбәндәге эчтәлекле 1.8, 1.9 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.8. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләр тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре»; |

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.5 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.5. | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы» билгесе»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

III бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләре өчен эш вакыты (эш хакы ставкасы өчен педагогика эше сәгатьләре нормасы) мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләре өчен эш вакытының кыскартылган озынлыгыннан чыгып, атнасына 36 сәгатьтән артмаган күләмдә

билгеләнә, ул укыту (уку) эшен, тәрбия эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи йөкләмәләрдә һәм эш вакыты режимында каралган башка педагогик эшне үз эченә ала.»;

IV бүлектә:

2 пунктта 1 таблицаның 55 пунктындагы 2 графада «Тимераякта фигуралы шуу» сүзләрен «Спорт аэробикасы» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

VI бүлектә:

2.5 пунктчаның унынчы абзацында «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе Мәгариф министры)» сүзләрен - «Министра просвещения Российской Федерации (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрының, Россия Федерациясе Мәгариф министрының)» сүзләренә, «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының)» сүзләрен «Россия Федерациясе просвещения министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының)» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфасы буенча» сүзләрен өстәргә;

8.10 пунктчада «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

8.11 пунктчаның бишенче, җиденче абзацларына «һәм төп вазыйфасы (укытучылар һәм мөгаллим вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

VII бүлектә:

8 пунктта «кимендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

VIII бүлекнең 9 нчы пунктындагы өченче, алтынчы – тугызынчы абзацларында «физик культура һәм спорт өлкәсендә» сүзләреннән соң «һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмасы» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 1 таблицасында:

«Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикаларының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе просвещения министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)»;

түбәндәге эчтәлекле 1., 1.10 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.9. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.10. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләр тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре»; |

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.6. | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы» билгесе»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

III бүлектә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләре өчен эш вакыты (эш хакы ставкасы өчен педагогика эше сәгатьләре нормасы) мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләре өчен эш вакытының кыскартылган озынлыгыннан чыгып, атнасына 36 сәгатьтән артмаган күләмдә билгеләнә, ул укыту (уку) эшен, тәрбия эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи йөкләмәләрдә һәм эш вакыты режимында каралган башка педагогик эшне үз эченә ала.»;

2.1 пунктчада:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 – 15 кеше – барлык һөнәрләр буенча гамәли дәресләр үткәргәндә һөнәри белем бирү оешмалары өчен, ә катлаулы җиһазларга хезмәт күрсәтү, куркыныч эшләрне башкару белән бәйле һөнәрләр буенча – 8 – 10 кеше.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Милли телдә укыта торган һөнәри белем бирү оешмаларында чит тел, туган тел һәм әдәбият, рус теле һәм әдәбияты буенча дәресләр уздырганда, информатика һәм исәпләү техникасы, физика һәм химия (гамәли дәресләр вакытында) буенча төркемне ике төркемчәгә бүлү рөхсәт ителә: шәһәр һөнәри белем бирү оешмаларында, әгәр төркем 25 кешене тәшкил итсә, авылда - 20дән дә ким булмаган кеше булса.»;

5.13 пунктчада «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

V бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Язмача эшләр тикшерү (дәфтәрләр тикшерү) өчен түләү түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{nz}^{pt} = \left(\sum O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P\right) \times D_{pt},$$

монда:

$B_{nz}^{pt}$ – язмача эшләр тикшерү (дәфтәрләр тикшерү) өчен түләүләр күләме;

$O_b$ – гомуми белем бирү оешмасының педагогика хезмәткәренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$H_f$ – гомуми белем бирү оешмасында предмет буенча педагогика эшен алып баруның гамәлдәге сәгатьләре саны;

$Y_f$ – гомуми белем бирү оешмасында педагогика хезмәткәре күрсәтә торган хезмәтләрнең гамәлдәге саны;

$H_N$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән гомуми белем бирү оешмаларында педагогика хезмәткәрләренең эш хакын база ставкасы өчен сәгатьләр нормасы;

$Y_N$ – гомуми белем бирү оешмасында педагогика хезмәткәрләре күрсәтә торган хезмәтләрнең норматив саны;

P – китап чыгару продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, ләкин төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаска тиеш;

$D_{pt}$ – язма эшләрне тикшергән (дәфтәрләр тикшергән) өчен өстәмә түләү күләме, ул 1 нче таблицасында китерелгән.»;

VI бүлектә:

2.3 пунктчаның унынчы абзацында «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе Мәгариф министры)» сүзләрен - «Россия Федерациясе просвещения министры (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрының, Россия Федерациясе Мәгариф министрының)» сүзләренә, «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының)» сүзләрен «Россия Федерациясе просвещения министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының)» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «төп эш урыны буенча» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфасы буенча» сүзләрен өстәргә;

7.11 пунктчаның бишенче, җиденче абзацларына «һәм төп вазыйфасы (укытучылар һәм мөгаллим вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 1 таблицасында:

«Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикаларының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе просвещения министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)»;

түбәндәге эчтәлекле 1.8, 1.9 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.8. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләр тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре»; |

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.5 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.5. | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы» билгесе»; |

Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр,

белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең V бүлегендәге 3 нче пунктның алтынчы абзацында «кимендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекнең 3 нче пунктында «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының» сүзләрен «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 сентябреннән барлыккка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә, әлеге карарның 1 пунктындагы егерме дүртенче абзацтан тыш, аның гамәле карар басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин